| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 октябрь 2022ел. Иске Тәрбит ав. № 11

Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең Башкарма комитеты белән берлектә, агымдагы елның 1 ноябренә кадәр Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең чираттагы финанс елына план чорына бюджет турындагы карар проектына материаллар әзерләргә, шул исәптән:

1) агымдагы елның узган чорында Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә алдан йомгаклар һәм агымдагы финанс елында социаль-икътисадый үсешнең көтелгән нәтиҗәләре;

2) агымдагы финанс елында Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләү;

3) Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы;

4) Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре проекты;

5) чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең эчке алынмалары программасы проекты;

6) Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең муниципаль гарантияләр программасы проекты;

7) Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет кредитлары бирү программасы проекты;

8) бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәпләре;

9) муниципаль бурычның өске чиге турында мәгълүмат: чираттагы финанс елы ахырына һәм план чорының һәр елы ахырына;

10) чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлегенең берләштерелгән бюджетының төп характеристикаларын фаразлау (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты);

11) бюджет проектына финанс-икътисадый нигезләү.

2. Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына керемнәр һәм чыгымнар фаразын билгеләү максатларында Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тапшырырга:

1) агымдагы елның 20 октябренә кадәр Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторы - җирле үзидарә органнарына чираттагы финанс елына һәм план чорына Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджетына алар администрацияли торган керемнәр фаразын;

2) Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлегенең бюджетын планлаштыру субъектларына:

агымдагы елның 15 октябренә кадәр - чираттагы финанс елына һәм план чорына чыгым йөкләмәләренең башлангыч реестрлары;

агымдагы елның 15 октябренә кадәр - чираттагы финанс елында финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән бюджет акчаларын тотуга китергән норматив хокукый актларның гамәлдә булуын үз көчен югалткан дип тану яисә туктатып тору турындагы тәкъдимнәр;

агымдагы елның 15 октябренә кадәр - Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге бюджеты исәбеннән чираттагы финанс елында һәм муниципаль гарантияләрнең планлы чорына алдан заявкалар алу;

агымдагы елның 20 октябренә кадәр - Россия Федерациясе бюджетларының бюджет классификациясе нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауның иң чик күләмнәрен бүлү.

3. Кайбыч муниципаль районының Финанс - бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән срокларда чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпләү өчен башлангыч күрсәткечләрне килештерергә;

2) агымдагы елның 20 октябренә кадәр Кайбыч муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауның иң чик күләмнәрен җибәрергә;

3) агымдагы елның 25 октябренә кадәр Кайбыч муниципаль районы бюджеты акчаларын баш урнаштыручылар тарафыннан тапшырылган чыгымнарны Россия Федерациясе чыгымнарының бюджет классификациясе нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына финанслауның иң чик күләмнәрен бүлүне карарга;

4) агымдагы елның 01 ноябренә кадәр «Кайбыч муниципаль районы авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турында» карар проектын әзерләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге https:/styaberdin.kaybici.tatarstan.ru/ веб.адресы буенча

Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче В.Г.Тимофеев